РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.04.2020 № 617-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында” 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче, аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра торган хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләрне билгеләргә:

ай саен, эшләнгән чорга пропорциональ рәвештә, 1 111 сум күләмендә стимуллаштыра торган, ләкин аена 1 111 сумнан да артык булмаган өстәмә түләү;

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче, аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Саба муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра торган хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибен расларга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
______________________
______________________
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче, аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Саба муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – оешмалар) гамәлгә ашыра торган хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләр бирү тәртибен һәм шартларын билгели:

ай саен, эшләнгән чорга пропорциональ рәвештә, 1 111 сум күләмендә стимуллаштыра торган, ләкин аена 1 111 сумнан да артык булмаган өстәмә түләү.

2. Оешма хезмәткәрләренә-яшь белгечләргә акчалата түләүләр Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына Саба муниципаль районы бюджетына каралган акчалар хисабына башкарыла.

3. Оешманың хезмәткәре – яшь белгеч дип, 30 яшькә кадәрге һәм аны да кертеп, беренче тапкыр көндезге формада һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирү программалары - бакалавриат, специалитет, магистратура, аспирантура программалары буенча дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаган (алга таба - һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү мәгариф оешмасы), һәм һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаган елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча, һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе нигезендә, хезмәт килешүе буенча оешмага түбәндәге вазифаларга - физкультура буенча инструктор, педагог-оештыручы, педагог-психолог, адаптив физик культура буенча инструктор-методист, адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист, тренер, адаптив физик культура буенча тренер-укытучы, хореограф, тренировка процессы администраторы, адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы вазифаларына эшкә алынган Россия Федерациясе гражданины танылa.

4. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен бирелә торган стимуллаштыручы өстәмә түләү алар эшкә урнашкан айдан соң килгән айның 1 көненнән башлап билгеләнә һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфада өзлексез эшләү шарты белән аны билгеләү датасыннан соң беренче өч ел дәвамында түләнә.

Хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар оешма боерыгы белән раслана.

Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә акчалар түләү түбәндәге вакыт аралыгында озынайтыла:

– Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хәрби хезмәт итү яки альтернатив граждан хезмәте үтү;

– йөклелек һәм бала табуга бәйле ял, кечкенә баланы аңа өч яше тулганчы карау һәм тәрбияләү;

– аспирантурада көндезге бүлектә белем алу.

5. Хезмәткәр - яшь белгеч башка оешмага әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазифага күчкәндә, 30 көннән дә артык булмаган ял вакыты рөхсәт ителә.

6. Оешмадагы кеше санының яисә штатның кыскаруына бәйле рәвештә хезмәткәрне – яшь белгечне эштән чыгарган очракта һәм ул башка оешмага әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазифага эшкә урнашканда, 60 көннән дә артык булмаган ял вакыты рөхсәт ителә.

7. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

8. Хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү төп вазифа буенча һәм эше әлеге хезмәткәр - яшь белгеч тарафыннан эчке берләшү шартларында башкарыла торган вазифа буенча, әмма бер ставкадан да артык булмаган күләмдә билгеләнә.

9. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times \frac{H_f}{H_n},$$

монда:

D – хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме, сум;

P – хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә аена 111 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә түләү;

Hf – хезмәткәр - яшь белгеч тарафыннан эшләнгән сәгатьләрнең факттагы саны, сәгать;

Hn - спорт резервын әзерләүне оештыручы хезмәткәрләрнең хезмәт хакының база ставкасы өчен сәгать нормасы, сәгать.

10. Оешмалар, ай саен, агымдагы елның 5 числосына кадәр, Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (алга таба текст буенча – ФБП ) түбәндәге документларны тапшыралар:

– акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга акча бирү турында гариза;

– оешманың хезмәткәрләре – яшь белгечләре реестры.

11. ФБП әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән документларны, алар кергән көннән, эш көннәре дип исәпләнгән биш көнлек срокта карый.

Оешма әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын яки югарыда аталган пункт таләпләренә туры килми торган документларны тапшырган очракта, ФБП гаризаны кире кайтара һәм биш көн эчендә оешмага, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, хәбәр итә.

Оешма, гаризаны кире кайтару турында хәбәрнамә алган көннән алып, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән документларны кабат тапшыра.

12. Оешманың хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү әлеге максатларга оешмага субсидия бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

13. ФБП ай саен оешмаларның шәхси счетларына хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне тормышка ашыру өчен субсидияләр күчерә.

14. Агымдагы финанс елында оешма тарафыннан файдаланылмый калган субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетына билгеләнгән тәртиптә кире күчерелергә тиеш.

15. Оешма тарафыннан субсидияләр бирү шартлары бозылган очракта, ФБП язма таләбе нигезендә, субсидияләр, тиешле таләп алынган көннән соң 10 эш көне эчендә, билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

16. Оешманың субсидияләр бирү, шулай ук төзелгән килешү шартларының үтәлешен тикшерү Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан башкарыла.

17. Оешмалар хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне оешмалар тарафыннан билгеләнгән хезмәт хакын түләү вакытында бирүне тәэмин итәләр.